| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**11 февраль 2020 ел** **Чистай шәһәре** **№45/5**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
“Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең
җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш
Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлап, тикшергәннән соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районының “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән һәм төзелешләр кагыйдәләре буенча комиссия нәтиҗәсен һәм 2019 елның 18 нче декабрендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең Чистай муниципаль районы территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә, алар Чистай шәһәр Советының 19.12.2012 ел, №18/7 карары белән расланган (Чистай шәһәр Советының 2016 елның 30 июнендәге №7/1, 25.08.2016 ел № 8/4, 27.04.2017 ел № 14/5, 28.09.2017 ел 18/4, 02.11.2017 ел №19/2, 14.12.2019 ел №20/13, 21.03.2018 ел №23/5, 29.08.2018 ел №27/1, 24.10.2018 ел № 28/5, 25.12.2018 ел №30/12, 28.02.2019 ел №32/1, 30.04.2019 ел №34/6, 11.06.2019 ел №35/4, 04.09.2019 ел №37/3, 27.11.2019 ел № 41/4 карарлары редакциясендә):

- «Урта этажлы торак йортларда төзелеш зонасы» Ж-2 территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Бебель урамы, 103-д, чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры 16:54:110102:43 булган 286,0 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген, «Индивидуаль торак йортларда төзелеш зонасы» Ж-1 зонасына кертү өлешендә (1 нче кушымта);
- «Урта катлы торак йортларда төзелеш зонасы» Ж-2 территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Бебель урамы, 103-а, чикләрендәге территорияне, шул исәптән кадастр номеры 16:54:110102:42 булган 600,0 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген, «Индивидуаль торак йортларда төзелеш зонасы» Ж-1 зонасына кертү өлешендә (2 нче кушымта);
- “III класслы куркынычлык җитештерү-коммуналь объектлар зонасы” ПК-2 төзелешенең территориаль зонасы чикләрен үзгәртү өлешендә Чистай шәһәре, Учхоз тыкрыгы, шул исәптән кадастр номеры 16:54:180202:126, 12614,0 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген, «Спорт һәм спорт-тамаша билгеләнешендәге объектларны урнаштыру зонасы» Д-4 зонасына кертү өлешендә (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.


3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М. И. Ксенофонтовны йөкләргә.

Чистай муниципаль районының Д.А. Иванов
Чистай шәһәре башлыгы


Чистай шәһәр Советының
2020 елның 11 февралендәге
45/5 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:





Кертелә торган үзгәрешләр:




Чистай шәһәр Советының
2020 елның 11 февралендәге
45/5 номерлы карарына
2 нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:





Кертелә торган үзгәрешләр:



Чистай шәһәр Советының
2020 елның 11 февралендәге
45/5 номерлы карарына
3 нче кушымта

Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең территорияне шәһәр төзелеше зоналарына бүлү картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

